| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>Алькеевского<br>муниципального района | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>Әлки<br>муниципаль районы<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

Адрес: 422870, РТ, с. Базарные Матаки, ул. Крайнова, 56 тел: 8 (84346) 2-17-60

Адресы: 422870, РТ, Базарлы Матак авылы, Крайнов ур., 56 факс: 8 (84346) 2-17-60


**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 елның 25 мае 207№

Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 4 апрелендәге 143 номерлы карары белән расланган Әлки муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына керешүче зат һәм Әлки муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесенең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат тәкъдим итү турындагы Нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында.

Россия Федерациясе Хезмәт Кодексының 275 статьясы нигезендә Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 4 апрелендәге 143 номерлы карары белән расланган Әлки муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына керешүче зат һәм Әлки муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесенең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат тәкъдим итү турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

-3 пунктта «ел саен, хисап елыннан соң килүче елның 30 апреленнән дә соңга калмыйча» сүзләрен «ел саен, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү өчен билгеләнгән срокларда» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында»гы http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырып чыгарырга, Әлки муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Әлки муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе: И.В.Юсупов